КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2024 ел, 13 июнь г.Казань № 421

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Социаль әһәмиятле йогышлы авыруларны кисәтү һәм аларга каршы көрәш чараларын тормышка ашыруга чыгым йөкләмәләрен финанслар белән тәэмин итү тәртибен һәм Социаль әһәмиятле йогышлы авыруларны кисәтү һәм аларга каршы көрәш чараларын гамәлгә ашыруга дәүләт медицина оешмаларына субсидияләр бирү күләмен һәм шартларын билгеләү тәртибен раслау турында» 2019 ел, 29 март, 236 нчы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Социаль әһәмиятле йогышлы авыруларны кисәтү һәм аларга каршы көрәш чараларын тормышка ашыруга чыгым йөкләмәләрен финанслар белән тәэмин итү тәртибен һәм Социаль әһәмиятле йогышлы авыруларны кисәтү һәм аларга каршы көрәш чараларын гамәлгә ашыруга дәүләт медицина оешмаларына субсидияләр бирү күләмен һәм шартларын билгеләү тәртибен раслау турында» 2019 ел, 29 март, 236 нчы карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2019 ел, 20 сентябрь, 852 нче; 2022 ел, 15 август, 832 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

әлеге карар белән расланган Социаль әһәмиятле йогышлы авыруларны кисәтү һәм аларга каршы көрәш чараларын тормышка ашыруга чыгым йөкләмәләрен финанслар белән тәэмин итү тәртибенең 4 пунктындагы икенче абзацында «туберкулезны ачыклау, аның микобактериясе сизгерлеген билгеләү һәм туберкулезны барлыкка китерүчесе күптөрле даруларга тотрыклы булган туберкулез белән авыручы затларны дәвалауны мониторинглау өчен диагностика чаралары сатып алуга» сүзләрен «туберкулезны ачыклау, туберкулез микобактериясе сизгерлеген билгеләү һәм туберкулезны барлыкка китерүчесе күптөрле даруларга

тотрыклы булган туберкулез белән авыручы затларны, пациентларны дәвалауны мониторинглау өчен диагностика чаралары сатып алуга» сүзләренә алмаштырырга;

әлеге карар белән расланган Социаль әһәмиятле йогышлы авыруларны кисәтү һәм аларга каршы көрәш чараларын гамәлгә ашыруга дәүләт медицина оешмаларына субсидияләр бирү күләмен һәм шартларын билгеләү тәртибендә:

1 пунктның өченче абзацында «туберкулезны ачыклау, аның микобактериясе сизгерлеген билгеләү һәм туберкулезны барлыкка китерүчесе күптөрле даруларга тотрыклы булган туберкулез белән авыручы затларны дәвалауны мониторинглау өчен диагностика чаралары сатып алуга» сүзләрен «туберкулезны ачыклау, туберкулез микобактериясе сизгерлеген билгеләү һәм туберкулезны барлыкка китерүчесе күптөрле даруларга тотрыклы булган туберкулез белән авыручы затларны, пациентларны дәвалауны мониторинглау өчен диагностика чаралары сатып алуга» сүзләренә алмаштырырга;

4 пунктта:

дүртенче абзацта «ачыклау» сүзе алдына «туберкулезны» сүзләрен өстәргә, «туберкулез белән авыручы затларны» сүзләрен «туберкулез белән авыручы затларны, пациентларны» сүзләренә алмаштырырга;

бишенче абзацта «ачыклау» сүзе алдына «туберкулезны» сүзләрен өстәргә, «туберкулез белән авыручы затларны» сүзләрен «туберкулез белән авыручы затларны, пациентларны» сүзләренә алмаштырырга;

8 пунктта:

өченче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасында туберкулезны билгеләүгә профилактик тикшерүләргә җәлеп ителгән затлар саны (кеше);»;

бишенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасында ВИЧ-инфекцияне билгеләүгә медицина тикшерүенә җәлеп ителгән затлар саны (кеше);»;

алтынчы абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасында ВИЧ-инфекция мәсьәләләре буенча мәгълүмат бирелгән 18 – 49 яшьтәге затлар саны (кеше).».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры
вазыйфаларын башкаручы Р.К.Нигъмәтуллин